ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ БАЙСАР АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423745, Иске Байсар авылы,
Мэктэп урамы, 44айорт.
Тел.(885552)3-44-53.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ СТАРОБАЙСАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423745, с. Старое Байсарово, ул.
Школьная, дом 44а

Тел.(885552) 3-44-53.

E-mail bay.akt@yandex.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**06.06. 2024 ел** **№ 9**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Төбәк салымнары суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Физик затларның җирле салымнары суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Иске Байсар авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

Совет рәисе Р.М.Кадыйров

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АКТАНЫШСКИЙ РАЙОН
ОГРН 1021605537458
р 05-11915/08
Совет Старобайсаровского сельского поселения Актанышского муниципального района Республики Татарстан
ИНН 1604000990